СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

28.11.2017 | 43-183

с. Набережные Моркваши

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативлары турында

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башкарма комитетының Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасы һәм 29.4 статьясы нигезендә эшләнгән, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге халкының тормыш-көнкүреше өчен уңай шартлар тәэмин итүгә һәм җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсен һәм мондый объектларның территориаль яктан мөмкин булган максималь дәрәҗәдә үтемле булуын исәпләү күрсәткечләрен билгеләүгә юнәлдерелгән озак вакытка исәпләнгән шәһәр төзелеше сәясәтен булдыру максатыннан эшләнгән җирле нормативлар турында мәгълүматны тыңлаганнан соң,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын расларга (№1 кушымта).
2. Бу карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Бу карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советының экология, табигый ресурслар һәм төзекләндерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ______________И.Х.Гаязов